ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2022 Баулы шәһәре №257

2023 елда Баулы муниципаль
районы муниципаль мәгариф
учреждениеләре укучыларын
туклану белән тәэмин
итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 нчы маддәсе, «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында (күрсәтелгән мәгариф учреждениеләрендә белем алучылар санының 100 процентын колачлаучы) башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар туклануын оештыру буенча чаралар исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукландыруның уртача бәясенә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 3 октябрендәге 1065 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында” 2022 елның 1сентябрендәге 934 номерлы карары белән, муниципаль мәгариф учреждениеләре укучыларын тулы кыйммәтле туклану белән тәэмин итү, СанПиН 2.4.5.2409-08 “Гомуми белем бирү

учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру” турындагы караның сәламәт туклануны оештыру өлешендә таләпләрен үтәү максатларында, шулай ук аерым категориядәге укучыларга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Баулы муниципаль районы бюджетыннан район һәм шәһәр мәгариф учреждениеләрендә ташламалы кайнар туклануны оештыруны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә субвенцияләр бирү буенча вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

2. Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениесендә уку чорында бер укучыга исәпләнгән көнлек кайнар туклану бәясенең күләмен 2023 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгечә билгеләргә:

бюджет исәбеннән:

- шәһәр һәм авыл мәгариф учреждениеләренең 1-4 класс укучылары өчен - 64 сум 19 тиен;

- 5-11 сыйныф укучылары өчен - 8 сум 80 тиен;

ата-ана кертемнәре исәбеннән:

- 5-11 сыйныф укучылары өчен:

шәһәрдә: иртәнге аш - 15 сум, төшке аш - 48 сум 60 тиен;

авылда иртәнге аш - 15 сум, төшке аш - 37 сум 80 тиен.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) кулланып, социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров